СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2020 Әгерҗе шәһәре № 3-14

Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Муниципаль районнарга аерым бюджет вәкаләтләрен бирү турында килешүләр төзү тәртибен җайга сала торган документларны имзалау һәм муниципаль норматив хокукый актлар кабул итү турында» 2020 елныж 01 сентябрендәге 21-53-10-2318 номерлы хатын үтәү максатында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелгән Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
18.11.2020 ел, № 3-14
карары белән расланган

Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе

1. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»Федераль закон) нигезендә эшләнде.

2. Район составына керүче аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, әлеге җирлекләрнең бюджетларыннан Район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен тапшыру турында Районның җирле үзидарә органнары белән килешү төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта районның җирле үзидарә органнары җирлек территориясендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча районның җирле үзидарә органнарына аерым вәкаләтләр бирү турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Районга җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру өчен Әгерҗе муниципаль районы Советы район составына керүче җирлекләр советларына җирлек вәкаләтләренең бер өлешен аларга тапшыру тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә. Аерым вәкаләтләрне тапшыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләрнең инициаторлары булып Әгерҗе муниципаль районы җирлекләре Советлары да тора.

4. Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру мәсьәләләре Район Советы һәм җирлекләр Советы утырышларында карала һәм карарлар рәвешендә рәсмиләштерелә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирлекләр вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары арасында төзелә.

Күрсәтелгән килешүләр билгеле бер срокка төзелә, аларның гамәлдә булуын туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләрдә, шул исәптән вакытыннан алда, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле

бюджетара трансфертларның әлеге өлештә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибендә, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тота.

6. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кирәкле акчалар каралган район һәм җирлекләр бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрне формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Финанс чараларын максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлек бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

7. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен муниципаль мөлкәт түләүсез вакытлы файдалану шартнамәсе нигезендә тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе ашыгыч рәвештә һәм Килешүнең гамәлдә булу срогына төзелә.

8. Бюджет процессын оештыру һәм җирлекләрнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу буенча килешүләр нигезендә тапшырылган аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Районның җирле үзидарә органнары үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланалар.

9. Җирлекнең вәкаләтләрен тапшырган җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала.

10. Килешүнең гамәле вакытыннан алда туктатыла:

- Яклар килешүе буенча;

- берьяклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

11. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Район җирле үзидарә органы файдаланылмаган финанс чараларын һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.

12. Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.